**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 38-6 «24» февраль 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 200 елның 2 декабрендәге 51 номерлы "Авыл җирендә, Актүбә шәһәр тибындагы поселокта эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында" карарына үзгәрешләре кертү хакында (2020 елның 14 декабрендәге 24-3 номерлы карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын фаразланган үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсенең 24,25 пунктларын үтәү йөзеннән,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 200 елның 2 декабрендәге 51 номерлы "Авыл җирендә, Актүбә шәһәр тибындагы поселокта эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында" (2020 елның 14 декабрендәге 24-3 номерлы карар редакциясендә)карарына түбәндәге үзгәрешәрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Авыл җирендә, Актүбә шәһәр тибындагы поселокта эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын алу шарты булып, Россия Федерациясе

бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү буенча бурыч булмау тора.».

1.2. «3,4» пунктларны «4,5»пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга:http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының бюджет, салымнар, финанслар, икътисад һәм социаль мәсьәләләр буенча даими комиссияләренә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин